ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР**

“06” август 2019 ел Калмия авылы №19

**“Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннарны билгеләү турында”**

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 маддәсе 8 өлеше һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» 2019 елның 10 июлендәге 67/516 санлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:
– Калмия авылы, Яшьләр ур., 24 й. (Исполком)
– Калмия авылы, Р.Хаҗиев ур., 52Б й. (мәгълүмат стенды)
– Калмия авылы, Р.Хаҗиев ур., 53В й. (мәгълүмат стенды)
– Кырныш авылы, Үзәк ур., 62А й. (мәгълүмат стенды)
– Малтабар авылы, Октябрьская ур., 12В й. (мәгълүмат стенды)

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ә.Гарипов